Сабак

## Исегездә калдырыгыз һәм балаларыгызга төшендерегез

**«Ләә иләәһә иллөллаһу Мөхәммәде Расүлуллаһ»**, дип Иманыгызны яңартып торыгыз.

***

Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылмаган кеше шайтанга сәҗдә кыла.

***

**«Әссәламегаләйкүм»** - дөньяда да, ахирәттә дә сәламәт яшәгез дигәнне аңлата.

***

**Мөселман** - буйсынучы дигән сүз.

***

**Сөннәт** - юл, традиция дигән мәгънәдә.

**Белегез!**
Асыл максат -
Аллаһыдан куркып,
Аңа
һәрдаим
гыйбадәт кылу.

Асыл максатын
онытмаган
кеше
бәхетле булыр,
уңышка,
Аллаһының
рәхмәтенә ирешер.

**Тарих битләреннән**
**1236 ел.**
780 ел элек «Кыйссаи Йосыф» китабының авторы - Кол Гали вафат булды.

***

**1260 ел.**
Бәркә хан, Алтын Урда ханнарыннан беренче булып, Исламны кабул итә.

***

**1716 елда,**
Петр I әмере белән, Коръән беренче тапкыр урыс теленә тәрҗемә ителә.

## Дин әһеленең фикере

«Дөньяи өчен ахирәтегезне сатмагыз. Яхшы кешеләргә якын булыгыз».

**Риза ФӘХРЕДДИН.**

## Асыл фикер

Татарстан Дәүләт советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Разил Вәлиев:**
«Ни өчен татар халкы сакланып калды? Безгә Ислам дине куәт бирде. Халык - Ислам динен, Ислам дине халыкны саклап калды».

## Белегез!

17 - 18 нче гасырларда
Европада
Боз океаны
(Северно-Ледовитый океан)
Татар океаны дип аталган.

## Татарча еллмаеп алыйк!

- 5 яшьтән 12 яшькә кадәр балаларны тәрбияләү буенча берәр нәрсә бармы сездә?
- Менә, бик әйбәт солдат каешы бар.

Мәгълүматларны **Шамил БАҺАУТДИН** туплады.

## Фәкыйрьләр чакырылмаган табын табын түгел

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәләм әйтте:**
«Начар тәгам (ризык) шундый тәгам ки, байлар чакырылып, фәкыйрьләр чакырылмаган табында бирелгән тәгамдер».

## Асыл фикер

«Әгәр минем Аллаһы Тәгалә кабул итәчәк бер генә догам булса, мин аны патша өчен кылыр идем. Әгәр үзем өчен генә сорасам, файдасы миңа гына булачак. Патша өчен сорап, ул изгелеккә ирешсә, барлык халык изге булачак».

**Фудаил** бин **ГИЯД.**

## Бурычка бирү - сәдакадан өстенрәк

**Җәбраил г-м:**
«Чөнки сәдака байга да, фәкыйрьгә дә бирелә. Ә бурычка акча фәкать ихтыяҗы булган (хәле мөшкел) кешегә генә бирелә».

Бизәп сөйләшик

## Аллаһы Тәгалә мәдәд бирсен!

**Пәрәвезгә эләккән чебен кебек, тыпырчыну.**
(Биться, как рыба об лед)

**Барып чыкмады.**
(Боком вышло)

**Син, туганкай, миңа юкә чәе какма.**
(Ты, брат, мне зубы не заговаривай)

**Бәла тагу.**
(Вешать собак)

**Кызмача булу.**
(Быть на взводе)

**Алай-болай иткәнче.**
(Пока суд да дело)

**Дуамал кеше.**
(Сумасброд)

**Мәхшәр**
(Суматоха)

**Маташып торасы да юк.**
(Овчинка выделки не стоит)

**Чүлмәкчедән күрмәкче; эт чаба дип, бет чаба.**
(Куда конь с копытом, туда и рак с клешней)

**Ит юкта үпкә тансык.**
(На безрыбье и рак - рыба)

**Якасыннан алу.**
(Брать за горло)

**Эш әле башланмаган да, бернәрсә дә әзер түгел.**
(Конь не валялся)

**Эч поша.**
(Тоска берет)

**Юләргә акыл сату.**
(Метать бисер перед свиньями)

**Аллаһы Тәгалә мәдәд бирсен!**
(Бог в помощь!)

Мәгълүматларны **Шамил БАҺАУТДИН** туплады.

**Укучыларыбыз гәҗитә турында**

## «Сәлам» гәҗитәсен мин ун ел буена укыйм»



«Сәлам» гәҗитәсен күп еллар яратып укыйм. Үзем өчен бик күп кирәкле мәгълүмат туплыйм.

Намаз вакытларын биреп барасыз, Аллаһының рәхмәте яусын.

Гәҗитә үзенчәлекле булуы белән аерылып тора. Ул башка басмаларны кабатламый. Үз йөзе, үз кыйблась, үз эчтәлеге.

Һәр мәкаләнең йөзем төше бар. Ул да булса - әхлаки, дини тәрбия.

Бер генә буш язма да юк. Һәрберсе - файдалы, тирән мәгънәле.

«Сәлам» гәҗитәсенә озын гомер телим. Безне, укучыларны, куандырып, озак еллар яшәргә язсын!

Самар шәһәрендә яшәүче **Идрис ВӘЛИЕВ** белән **Миләүшә ГАЗЫЙМ** сөйләште.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): "Шигырьдә хикмәт бар"**

## Яндырган, җырлаткан мәхәббәт!

Ярсыган йөрәккә
урын тар,
Күңелем түрендә
нидер бар!
Үзем дә
аңламас тойгы бу,
Әллә җыр,
әллә моң,
әллә зар?!

Кош булып йөрәгем
болынга ашкына,
Чәчкәләр исеннән
рәхәтлек кичерә!
Яндырган,
елаткан,
көйдергән,
җырлаткан,
Ул - минем
сөекле
хатыныма мәхәббәт!

**Зиннур КӘРИМОВ.**
Кызыл Су авылы.

**Магазин «Халяль»**
на территории минирынка
на пересечении улиц
Аминева и Ново-Садовой
В ассортименте:
колбасные изделия,
куры и субпродукты, домашняя выпечка, чай, восточные сладости, деревенская молочная продукция.
При покупке от 2000 рублей скидка 5%
**8-927=746-51-73** Гузель

## Игъланнар

**Просьба**
Медресе «Нур» г. Самары
(ул. Стара-Загора, 54)
**примет в дар небольшой б/у холодильник.**
Обращаться по телефону:
**8-927=705-24-91**
Альфия

**Внимание!**
В медресе «Нур» г. Самары, Стара-Загора, 54
(на территории Соборной мечети)
**нуждающиеся люди могут бесплатно получить**
использованную,
но в нормальном состоянии
**одежду** и **обувь**.
Также медресе принимает одежду и обувь для нуждающихся.
Обратиться по телефону:
**8-927=705-24-91** Альфия.

**Продается**
2-этажный
каркасный дом (71 кв. м)
в поселке Красный Яр
2016 г. постройки.
Обшит панелями,
скважина, канализация,
котел, водонагреватель.
Рассмотрим обмен на квартиру в городе самаре.
**8-917=112-14-16**

## Үз ишемне эзлим

Самарда яшәүче
54 яшьлек дини татар хатыны,
үз фатирында яши,
50 - 60 яшьлек
эчми торган тәртипле
татар ир-аты
белән танышырга тели.

**8-927=784-20-96**
Галия

Похвистневода яшәүче
26 яшьлек эчмәүче, тартмаучы,
югары белемле татар егете,
гаилә корыр өчен, 19 - 23 яшьлек
тәртипле татар кызы
белән танышырга тели.

**8-937=178-61-05**
Рәмис

25 яшьлек тәмәке тартмаучы,
хәмер-шәраб эчмәүче,
татар телен белүче ир-егет
динебез Ислам кануннары
буенча яшәүче кыз
белән гаилә корырга тели.

**8-937=06-13-111**
Марат

Тупли авылында
бөтен уңайлыклары
булган йортта яшәүче,
тырыш, эшчән 51 яшьлек
намазчы татар ир-аты
25 - 40 яшьлек
татар хатын-кызы
белән гаилә корырга тели.

**8-927=71-90-417**

55 яшьлек
татар ир-аты,
пенсиядә,
эшләп йөри,
торыр урыны бар,
татар хатыны белән
гаилә корырга тели.

**8-927=262-54-06**
Нәзиф

**Бездә игъланнар бушлай.**
Мәгълүматны
**Миләүшә ГАЗЫЙМ** туплады.
**8-937=207-08-88**